| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.11.2018 Казан ш. № 10-44/кс

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2017 елның 14 декабрендәге 10-113/кс номерлы карары белән билгеләнгән "Энергоресурс" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2019 елга каты коммуналь калдыкларны күмүгә озак вакытка исәпләнгән чик тарифларны үзгәртү турында

"Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару турында" 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында" 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең "Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында" 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы, "Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә җайга салына торган тарифларны билгеләү регламентын раслау турында" 2014 елның 16 июлендәге 1154-э номерлы боерыклары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә таянып, эчәргә яраклы суга һәм ташландык суны чыгаруга озак вакытка исәпләнгән тарифларны һәм җайга салына торган оешмаларның таләп ителгән тулаем табышын үзгәртү максатларында Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының "2018 - 2020 елларга "Энергоресурс" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчәргә яраклы суга һәм ташландык суны чыгаруга тарифлар билгеләү турында" 2017 елның 14 декабрендәге 10-113/кс номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылган көннән соң 10 көн эчендә үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
2018 елның 14декабрендәге 10-113/кс
номерлы карарына1нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
2018 елның 21 ноябрендәге 10-44/кс
номерлы карары редакциясендә)

Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы "Энергоресурс" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2018 – 2020 елларга, календарь бүленештә күрсәтеп, эчәргә яраклы суга һәм ташландык суны чыгаруга тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешманың исеме | Эчәргә яраклы суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | | | | | Ташландык суны чыгаруга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2018 ел | | 2019 ел | | 2020 ел | | 2018 ел | | 2019 ел | | 2020 ел | |
| | | - 2018 елның 1 гыйнварынннан алып 2018 елның 30 июненә кадәр | 2018 елның 1 июленнән алып 2018 елның 31 декабренә кадәр | 2019 елның 1 гыйнвары ннан алып 2019 елның 30 июненә кадәр | 2019 елның 1 июленнән алып 2019 елның 31 декабренә кадәр | 2020 елның 1 гыйнварын нан алып 2020 елның 30 июненә кадәр | 2020 елның 1 июленнән алып 2020 елның 31 декабренә кадәр | 2018 елның 1 гыйнварын нан алып 2018 елның 30 июненә кадәр | 2018 елның 1 июленнән алып 2018 елның 31 декабренә кадәр | 2019 елның 1 гыйнвары ннан алып 2019 елның 30 июненә кадәр | 2019 елның 1 июленнән алып 2019 елның 31 декабренә кадәр | 2020 елның 1 гыйнварын нан алып 2020 елның 30 июненә кадәр | 2020 елның 1 июленнән алып 2020 елның 31 декабренә кадәр |
| | Питрәч муниципаль районы | | | | | | | | | | | | |
| 1 | «Энергоресурс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | | | | | | | | |
| 1.1 | Халык (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән)* | 33,95 | 33,95 | 28,15 | 28,15 | 28,15 | 28,93 | 24,99 | 24,99 | 21,41 | 21,41 | 21,41 | 22,03 |
| 1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар НДСны исәпкә алмыйча күрсәтелгән) | 28,77 | 28,77 | 23,46 | 23,46 | 23,46 | 24,11 | 21,18 | 21,18 | 17,84 | 17,84 | 17,84 | 18,36 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясындагы 6 пунктын гамәлгә ашыру максатларында аерым күрсәтелә

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
тарифларны кабул итүне оештыру, тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
2017 елның 14декабрендәге 10-113/кс
номерлы карарына 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
2018 елның 21 ноябрендәге 10-44/кс
номерлы карары редакциясендә)

Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы "Энергоресурс" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 2018 – 2020 елларга тарифларын җайга салуның озак вакытка каралган параметрлары

| № т/б | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешманың исеме тариф төре | Ел | Операцион норматив нигез дәрәҗәсе | Оперцион чыгымнарның нәтиҗәлелеге индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | су югалту дәрәҗәсе | электр энергиясенең чагыштырма кулланылышы |
| | | | мең сум | процент | процент | процент | кВт·сәг./куб.м |
| 1 | «Энергоресурс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | | |
| 1.1 | Эчәргә яраклы су | 2018 | 3 543,30 | 1 | - | - | 0,99 |
| | | 2019 | 3 669,23 | 1 | - | - | 0,99 |
| | | 2020 | 3 756,04 | 1 | - | - | 0,99 |
| 1.2 | Ташландык суны чыгару | 2018 | 3 722,10 | 1 | - | - | 0,51 |
| | | 2019 | 3 854,38 | 1 | - | - | 0,51 |
| | | 2020 | 3 945,58 | 1 | - | - | 0,51 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
тарифларны кабул итүне оештыру, тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге